ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15.11.2022г.**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 3140**

2023 елга 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәре баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясындагы 3[2] пунктының дүртенче абзацы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәре баш администраторлары исемлеген расларга.
2. Әлеге карар, 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорындагы бюджеттан башлап, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, ММЧ белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын тану:

«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 10 ноябрендәге 2826 номерлы;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 ноябрендәге 2826 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 134 номерлы;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 ноябрендәге 2826 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 16 февралендәге 329 номерлы;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 ноябрендәге 2826 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 12 июлендәге 1728 номерлы.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин